**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Базарные Матаки **КАРАР**

2022 елның 17 декабре 463№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 октябрендәге «Мәгариф, мәдәният һәм спорт муниципаль оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) ярдәм чаралары күрсәтү турында» 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 1 октябрендәге «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1212 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 октябрендәге «Мәгариф, мәдәният һәм спорт муниципаль оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) ярдәм чаралары күрсәтү турында» 391 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары күрсәтү турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер»

батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләрнең балалары, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә чаралар билгеләргә:».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче: Р.Х. Морадымов

Захарова Н.П.